**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Манзарас авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлеге**

# КАРАР

**2022 елның 26 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Өлге авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өлге авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылы территориясен төзекләндерү;
- Өлге авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;
- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;
- Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 299 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 159.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 157 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Өлге авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокны хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Өлге авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өлге авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылы территориясен төзекләндерү;
- Өлге авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;
- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр

өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;

- Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина